**РАСЛЫЙМ**
Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнарының Диния нәзарәте рәисе, Мөфти
Камил хәзрәт Сәмигуллин
________________________
«14» декабрь 2017 ел

**РАСЛЫЙМ**
«Россия ислам институты» ректоры
Р.М. Мөхәммәтшин
________________________
«14» декабрь 2017 ел

Гарипова-Хәсәншина В.М., Айдарова С.Х., Гимазова Р.А.

# ТАТАР ТЕЛЕН БАШЛАП ӨЙРӘНҮЧЕЛӘР ӨЧЕН ПРОГРАММА

**Казан – 2017**

# ЭЧТӘЛЕК


Кереш сүз ........ 3

ПРОГРАММАНЫҢ ЭЧТӘЛЕГЕ ........ 5

Беренче тема ........ 5

Исәнләшү һәм танышу. Аралашу әдәбе ........ 5

Икенче тема ........ 6

Гаилә, йорт, ата-ана ........ 6

Өченче тема ........ 8

Ислам этикеты. Ризык. ........ 8

ДҮРТЕНЧЕ ТЕМА ........ 9

Атна көннәре. Ел фасыллары ........ 9

БИШЕНЧЕ ТЕМА ........ 11

Мәчет ........ 11

АЛТЫНЧЫ ТЕМА ........ 12

Дини бәйрәмнәр, истәлекле көннәр, изге кичәләр ........ 12

КАБАТЛАУ ........ 14

Фонетик зарядка өчен сүзләр ........ 15

Файдаланылган әдәбият исемлеге ........ 17

# КЕРЕШ СҮЗ

Әлеге программа мәчетләрдә оештырылучы татар теле курслары өчен махсус төзелде. Ул коммуникатив һәм эшчәнлекле технологияләргә нигезләнә. Программада татар телен башлап өйрәнү өчен 36 сәгать карала. Ул алты темадан гыйбарәт булып, үз эченә әлеге темаларга бәйле лексик берәмлекләрне, сөйләм калыпларын өйрәнүне ала һәм аларны, сөйләм ситуациясенә карап, дөрес, урынлы куллана белү күнекмәләрен формалаштыру һәм ныгытуны максат итә.

Программада түбәндәге темалар урын ала:

1. Исәнләшү һәм танышу. Аралашу әдәбе.
2. Гаилә, йорт, ата-ана.
3. Ислам этикеты. Ризык.
4. Атна көннәре. Ел фасыллары.
5. Мәчет.
6. Дини бәйрәмнәр, истәлекле көннәр, изге кичәләр.

Әлеге темаларны үзләштерүгә 33 сәгать бирелә. Кабатлауга 3 сәгать карала. Курс ахырында, белем һәм күнекмәләрне тикшерү максатында, вәгазьне тыңлап аңлауга юнәлдерелгән биремнәр эшләтелә.

Грамматик материал лексик-грамматик төзелмәләр формасында өйрәнелә. Аларны үзләштерү сөйләм ситуцияләре нигезендә оештырыла.

Программа түбәндәге максатларны тормышка ашыруны күздә тота:

- авазларны ишетеп аера һәм дөрес әйтә белү;
- җөмләләрне дөрес әйтү;
- аралашу барышында, коммуникатив максаттан чыгып, актив лексикадан файдалану; өйрәнелгән аралашу темаларына караган лексик берәмлекләрне һәм сүтезмәләрне таный белү.
- өйрәнелгән җөмлә калыпларын сөйләмдә куллану;
- татар телендә сөйләшүчеләр белән телдән аралашуга әзер булу;
- сөйләм әдәбе үрнәкләрен кулланып, гади диалогларда катнашу;

- үзе, гаиләсе, дини бәйрәмнәр, ризык, мәчет, хаҗ турында сөйләү;
- текстны укып яки тыңлап, эчтәлеге буенча сорауларга җавап бирү;
- төзелеш-корылыш ягыннан катлаулы булмаган вәгазь текстларын ишетеп аңлый алу.

Программада уку-укыту процессын оештыруда заманча технологияләр һәм эш формалары куллану да карала.

## ПРОГРАММАНЫҢ ЭЧТӘЛЕГЕ

## БЕРЕНЧЕ ТЕМА

### Исәнләшү һәм танышу. Аралашу әдәбе

### (5 сәгать)

Тема үз эченә татар телендә аралашу әдәбенә нисбәтле лексик берәмлекләрне, сөйләм калыпларын ала һәм аларны, сөйләм ситуациясенә карап, дөрес, урынлы куллана белү күнекмәләрен формалаштыру һәм ныгытуны максат итеп куя.

Исәнләшү. Танышу. Саубуллашу. Әңгәмәдәшкә мөрәҗәгать. Хәл сорашу. Үзең турында кыскача текст төзеп, аны сөйләргә өйрәнү.

Татар теленең авазлар системасы, калын һәм нечкә сузыклар хакында мәгълүмат бирү. Татар теленең үзенчәлекле авазларын дөрес әйтергә өйрәтү. Һәр дәрес алдыннан, авазларның дөрес әйтелешен һәм мәгънәсен истә калдыру максатында, аудиоматериаллар һәм презентация ярдәмендә “фонетик зарядка” ясату. Фонетик зарядка өчен лексик материалны темага бәйле сайлау.

Тема кысаларында *-мы/-ме* сорау кисәкчәләрен сөйләмдә куллана белергә өйрәтү. Хәбәрнең җөмлә ахырында килүенә игътибарны юнәлтү. Күплек һәм берлек сандагы исемнәрне, зат алмашлыкларын сөйләмдә куллану. *Түгел* сүзе ярдәмендә инкарь итү, раслау һәм инкарь җөмләләр төзү.

***Лексик минимум:*** Әссәламү галә́йкем, вәгаләйкемүс-сәлам, исәнләшү́. Исә́нме(-сез)! Са́умы(-сыз)! Сәла́м! Хәерле́ иртә́! Хәерле́ көн! Хәерле́ кич! Рәхи́м итегез! Хәлләрегé з ни́чек? Сәламәтлегегé з ни́чек? Рәхмә́т, бик яхшы́! Са́у бул(-ыгыз)! Күрешкәнгә́ кадә́р! Очрашканга́ кадә́р! Исә́н бул(-ыгыз)! Исән-са́у булыгыз! Иртәгәгә́ кадә́р! Кичкә́ кадә́р! Ху́ш(-ыгыз)! Хәерле́ юл! Уңышла́р сезгә́! Риясызда́н булсы́н! Корба́н бәйрәмé мөбарә́к булсы́н! Ураза́ бәйрәмé мөбарә́к булсы́н! Икé дөнья́ бәхетé н насы́йп итсé н! Изгé җомгала́р белә́н!

Минé м исемé м ... . Минé м фами́лиям ... . Ә Сезнé ң исемегé з ни́чек? Бик ша́тмын. Танышуыбызга́ бик ша́тмын. Ул тәкъва́ кешé . Сез хаклы́. Зинһа́р,

ки́чер(-егез). Гафу́ үтенә́м. Мин гаепле́. Гафу́ ит(-егез), мин ялгышка́нмын. Гафу́ ит(-егез), мине́м эше́м бар. Рәхмә́т. Бик зур рәхмә́т. Игътибарыгы́з өче́н зур рәхмә́т. Мин Сездә́н бик канәга́ть. Бе́рни түгел. Рәхи́м итегез. Аллаһны́ң кодрәте́ киң булсы́н! Аллаһны́ң рәхмәте́ яусы́н! Алла́һ ярдәменнә́н ташла́масын! Алла́һ бәрәкәтле́ тормы́ш бирсе́н! Алла́һ кабу́л кылсы́н! Файдалы́ гыйлемнә́р насы́йп булсы́н! Укыга́н намазларыбы́з кабу́л булсы́н! Алла́һ Тәгалә́ үзе́ сакласы́н!

Дин, пәйгамбә́р, мәче́т, аза́н, җомга́, има́м, кыйбла́, мәхәллә́, мөәдзи́н, Коръә́н, мөсли́м, әйе́, юк, түге́л, бу, мин, син, ул, без, сез, ала́р, шәке́рт, укытучы́, дәфтә́р, хәзрәт, әфәнде́, ханы́м, тута́ш.

***Сөйләм үстерү өчен эш төрләре:***

Диалоглар белән эш. Әзер диалогларны укып аңлау, алардагы сөйләм калыпларын истә калдыру. Диалогларны тәрҗемә итү, тулыландырып язу, рольләргә бүлеп уку. Грамматик формаларны сөйләм ситуациясе нигезендә аңлату. Тема буенча тәкъдим ителгән лексик берәмлекләрне һәм сөйләм этикеты үрнәкләрен файдаланып, мөстәкыйль рәвештә диалоглар төзү, үзара сөйләшү.

## ИКЕНЧЕ ТЕМА

## Гаилә, йорт, ата-ана

**(5 сәгать)**

Тема үз эченә татар телендә гаилә, йорт, туган-тумачалыкка караган лексик берәмлекләрне, сөйләм калыпларын ала һәм аларны, сөйләм ситуациясенә карап, дөрес, урынлы куллана белү күнекмәләрен формалаштыру һәм ныгытуны максат итә. Бу теманы үзләштергән кеше, гади җөмләләр ярдәмендә, гаиләсе, гаилә әгъзалары, үзе турында мәгълүмат бирә алырга тиеш.

Туганлык атамалары. Гаилә әгъзалары. Аларның һөнәрләре, шөгыльләре. Үзең һәм гаиләң турында сөйләү.

Иялек, юнәлеш, чыгыш һәм урын-вакыт килешләрен сөйләмдә куллана белергә өйрәтү, әлеге килешләргә нигезләнгән актив сөйләм калыплары белән таныштыру. “Сыйфат+исем” төзелмәләре ярдәмендә гаилә әгъзаларына характеристика бирү. Микъдар һәм тәртип саннары белән таныштыру, аларның кешенең туган елын, яшен, предметларның, объектларның санын әйтүдә дөрес кулланылышын аңлату. *Кая? Кайда? Кайдан? Кемнең? Нәрсәнең? Ничә? Ничәнче? Нинди?* сорауларына җавап бирә белергә өйрәтү. Тартым категориясе турында мәгълүмат бирү. Хәзерге заман хикәя фигыль формаларын сөйләмдә куллану күнекмәләрен формалаштыру.

***Лексик минимум:*** Әти́, әни́, дә́ү әти, дә́ү әни, апа́, абы́й, эне́, сеңе́л, кыз, ул, оны́к, оныкчы́к, игезә́к, бе́ртуган, ера́к туга́н, якы́н туга́н, әби́, баба́й, еге́т, кия́ү, кәлә́ш, киле́н, хаты́н, ир, каенана́, каената́, үги́ әни, үги́ әти, кода́, кодагы́й, туга́н-тумача́, таны́ш-беле́ш, балды́з, җизни́, кардә́ш, гаилә́.

Зур, кечкенә́, акыллы́, тыры́ш, эшчә́н, ялка́у, бик, мату́р, тату́, дус, карт, өлкә́н яшьтә́, яшь, җите́з, өлге́р, шук, шая́н, тәрбияле́, инсафлы́, миһербанлы́, намуслы́, дини́, итагатьле́, исә́н-са́у.

Бәрәкә́т, дәгъвә́т, дога́, зияра́т, нәсыйхә́т, госе́л, салава́т, тәһарә́т, ая́т, зәкят, мәүли́д, ника́х, тәүфыйклы́ бала́.

Һәм, белә́н.

Әтиемне́ң исеме́, аңа́ ... яшь, әниемне́ң исеме, яши́без, фати́р, йорт, туга́нмын, туга́н, -нчы/-нче елда́ туган (туганмын), булы́п эшли́, лаеклы́ ялда́, хә́зер эшлә́ми, укы́йм, укы́й, балала́р бакчасына́ йөри́, гаиләбе́з, урнашка́н.

***Фонетик зарядка.*** Аудиоматериаллар һәм презентация ярдәмендә “фонетик зарядка” ясату. Алдагы темада үтелгән сүзләрнең дөрес әйтелешен кабатлау, тәрҗемәләрен искә төшерү.

***Сөйләм үстерү өчен эш төрләре:***

Диалоглар белән эш. Әзер диалогларны укып аңлау, алардагы әзер сөйләм калыпларын истә калдыру. Диалогларны тәрҗемә итү, тулыландырып язу, әйтү. Грамматик формаларны сөйләм ситуациясе нигезендә аңлату. Тема буенча тәкъдим ителгән лексик берәмлекләрне һәм сөйләм калыпларын

файдаланып, мөстәкыйль рәвештә диалоглар төзү, үзара сөйләшү. Җөмләләргә сорау куя белү. Лексик тема буенча сөйләшү үткәрү. Сөйләмне ишетеп аңлау һәм җавап кайтару. Текстларны уку һәм төп эчтәлегенә төшенү, сорауларга җавап бирү. Таныш булмаган сүзләр белән эш. Текстның эчтәлеген сөйләү. Өйрәнелгән диалоглар, лексик материал нигезендә "Үзем турында", "Минем гаиләм" темалары буенча текст төзү, аларны сөйләргә өйрәнү.

## ӨЧЕНЧЕ ТЕМА

## Ислам этикеты. Ризык.

**(6 сәгать)**

Тема телне өйрәнүчене татар телендә ризык, җиләк-җимеш, яшелчә, савыт-саба атамалары белән таныштыруны, әлеге төр лексиканы сөйләмдә куллана белергә өйрәтүне максат итеп куя. Бу темага нисбәтле лексик берәмлекләрне һәм калыпларны үзләштергән кеше нинди ризыклар яратуы, ислам динендә табын артында утыру кагыйдәләре хакында гади сорауларга җавап бирә, үзе дә, сөйләм ситуациясенә карап сорау бирә, әңгәмә кора белергә, монологик сөйләм төзеп сөйли алырга тиеш.

Яшелчә, җиләк-җимеш. Савыт-саба. Ризык. Аш-су. Ислам динендә табын артында утыру кагыйдәләре.

"Сыйфат+исем" төзелмәләре ярдәмендә ризык, җиләк-җимеш һәм яшелчәләр хакында сөйләргә өйрәтү. Темага бәйле рәвештә, үткән заман хикәя фигыль формаларының, боерык фигыльләрнең сөйләмдә кулланылышы хакында мәгълүмат бирү. Килеш һәм тартым кушымчаларын сөйләмдә дөрес кулланылыш күнекмәләрен формалаштыру һәм ныгытуны дәвам итү.

***Лексик минимум:*** аш, боткá, пылáу, балы́к, ит, йомыркá, эремчéк, пилмә́н, бәлéш, ипи́, су, чәй, кесә́л, кымы́з, әйрә́н, сөт, ризы́к.

Бәрәңгé, кишéр, сугáн, чөгендéр, кыя́р, сарымсáк, борчáк, кәбестә́, боры́ч, алмá, чия́, курá җиләгé, карлыгáн, әфлисýн, җи́р җиләгé, каéн җиләгé, бакчá җиләгé, хөрмә́, балáн, миләш.

Ак, кара́, кызы́л, яше́л, зәңгә́р, сары́, ал, шәмәхә́, көрә́н, кызгылт-сары́ (әфлисун төсе), ачы́к зәңгә́р, соры́.

Ачы́, тозлы́, баллы́, салкы́н, кайна́р, куе́, сые́к, тозсы́з, тәмле́, тәмсе́з.

Чәйне́к, чынаяк, кала́к, кашы́к, чәнечке́, кәстру́л, эскәте́р, таба́, пыча́к, а́ш чүмече, өстә́л, урынды́к, а́ш бүлмәсе, тәлинкә́.

Ярат, кы́здыр, пе́шер, а́ша, эч, я́са, сал, бүл, су́ыт, җы́лыт, ка́йнат, чи́старт, ю, бо́лгат.

Хәлә́л, хәра́м, сөннә́т, хәди́с, сүрә́, важи́б, җәннә́т, җәһәннә́м, има́н, кыямә́т, ураза́, тәрави́х, фикъһ, әдә́п.

***Фонетик зарядка.*** Аудиоматериаллар һәм презентация ярдәмендә “фонетик зарядка” ясату. Алдагы темада үтелгән сүзләрнең дөрес әйтелешен кабатлау, тәрҗемәләрен искә төшерү.

***Сөйләм үстерү өчен эш төрләре:***

Сөйләм калыплары, сүзтезмәләр белән эш. Яңа лексик берәмлекләрне сүзтезмә һәм җөмлә эчендә карап истә калдыру. Диалогик һәм монологик сөйләмне үстерү. Әзер диалогларны укып аңлау, алардагы әзер сөйләм калыпларын истә калдыру. Диалогларны тәрҗемә итү, тулыландырып язу, әйтү. Грамматик формаларны сөйләм ситуациясе нигезендә аңлату. Тема буенча тәкъдим ителгән лексик берәмлекләрне һәм сөйләм үрнәкләрен файдаланып, мөстәкыйль рәвештә диалоглар төзү, үзара сөйләшү. Темага бәйле рәвештә, өйрәнелгән диалоглар нигезендә монологик сөйләм төзергә өйрәнү. Лексик тема буенча сөйләшү үткәрү. Сөйләмне ишетеп аңлау һәм җавап кайтару. Текстларны уку һәм төп эчтәлегенә төшенү, сорауларга җавап бирү. Таныш булмаган сүзләр белән эш. Текстның эчтәлеген сөйләү.

## ДҮРТЕНЧЕ ТЕМА

### Атна көннәре. Ел фасыллары

**(6 сәгать)**

Теманың максаты – атна көннәре, ел фасыллары, вакыт категориясенә караган лексик берәмлекләр һәм сөйләм калыплары белән таныштыру, аларны, сөйләм ситуациясенә бәйле рәвештә, дөрес куллана белү күнекмәләрен формалаштыру. Бу темага нисбәтле лексик берәмлекләрне һәм калыпларны үзләштергән кеше тема буенча әңгәмә кора белергә, монологик сөйләм төзеп сөйли алырга тиеш.

Табигать күренешләре, ел фасыллары хакында сүз барганда, сыйфатларның һәм рәвешләрнең кулланылышы, киләчәк заман хикәя фигыль белән таныштыру. Фигыльнең заман формаларын (хәзерге, үткән) һәм килеш кушымчаларын сөйләмдә дөрес куллану күнекмәләрен ныгытуны дәвам итү.

***Лексик минимум:*** кич, киче́н, иртә́, иртә́н, төн, төнлә́, көн, көндéз, кичә́, бүге́н, иртәгә́, җәй, кыш, көз, яз, коя́ш, җил, һава́ торышы́, табига́ть.

Дүшә́мбе, сишә́мбе, чәршә́мбе, пәнҗешә́мбе, җомга́, шимбә́, якшә́мбе.

Мөхәррә́м, Сәфә́р, Рабигыл-әүвә́л, Рабигыл-ахы́р, Җөмадел-әүвә́л, Җөмадел-ахы́р, Рәҗә́п, Шәгъба́н, Рамаза́н, Шәүвә́л, Зөлкәгъдә́, Зөлхиҗҗә́.

Җылы́, суы́к, салкы́н, озы́н, кыска́, җилле́, җилсе́з, кояшлы́, болытлы́, яңгырлы́, мату́р, караңгы́, якты́, ая́з.

Җил исә́, яңгы́р ява́, кар ява, яшенле́ яңгы́р, салава́т күпере́ чыга́, җитә́, бар, у́кы, кил, яз, (ике) тула́, туларга́, башланды́, тәмамланды́, яз (кыш, көз, җәй) җитте.

Сәга́ть, сәга́ть теле́, вакы́т. Сәга́ть ни́чә? Сәга́ть ни́чәдә? Вакы́т ку́пме?

***Фонетик зарядка.*** Аудиоматериаллар һәм презентация ярдәмендә “фонетик зарядка” ясату. Алдагы темада үтелгән сүзләрнең дөрес әйтелешен кабатлау, тәрҗемәләрен искә төшерү.

***Сөйләм үстерү өчен эш төрләре:***

Диалоглар белән эш. Әзер диалогларны укып аңлау, алардагы әзер сөйләм калыпларын истә калдыру. Диалогларны тәрҗемә итү, тулыландырып язу, әйтү. Сорау яки җавап репликаларын өстәп, диалоглар төзү. Грамматик формаларны сөйләм ситуациясе нигезендә аңлату. Тема буенча тәкъдим

ителгән лексик берәмлекләрне һәм сөйләм этикеты үрнәкләрен файдаланып, мөстәкыйль рәвештә диалоглар төзү, үзара сөйләшү. Лексик тема буенча сөйләшү үткәрү. Сөйләмне ишетеп аңлау һәм җавап кайтару. Текстларны уку һәм төп эчтәлегенә төшенү, сорауларга җавап бирү. Таныш булмаган сүзләр белән эш. Текстның эчтәлеген сөйләү. Темага бәйле рәвештә, өйрәнелгән диалоглар нигезендә монологик сөйләм төзергә өйрәнү.

## БИШЕНЧЕ ТЕМА

### Мәчет

### (6 сәгать)

Теманың максаты – мәчет темасына нисбәтле лексик берәмлекләр һәм сөйләм калыплары белән таныштыру, аларны, сөйләм ситуациясенә бәйле рәвештә, монолог һәм диалогларда дөрес куллана белү күнекмәләрен формалаштыру.

Мәчет. Аны тасвирлау. Госел. Тәһарәт. Намаз. Җомга намазы. Вәгазь.

Тема кысаларында *кирәк, кирәк түгел, тиеш, тиеш түгел, ярый, ярамый, мөмкин, мөмкин түгел* төзелмәләрен сөйләмдә куллана белергә өйрәтү. Хикәя һәм боерык фигыль формаларының сөйләмдә кулланылышын ныгытуны дәвам итү.

***Лексик минимум:*** Буй, гәүдә́, баш, муе́н, чәч, күз, каш, маңга́й, яңа́к, кола́к, авы́з, ире́н, керфе́к, теш, боры́н, тән, күкрә́к, кенде́к, терсә́к, аяк, кул, тез, бот, үкчә́, барма́к, таба́н.

Тәһарә́т ал, тырна́к кис, сөннәткә́ уты́рт, юы́н, үтәргә́ кирә́к, ке́регез, у́зыгыз, намазлы́к урыны́н чиста́ тот, бит ю, теш чистарт, чәч тара́, бар, кайт, ты́ңла.

Тәкби́р, тәсби́х, тәхли́л, өммә́т, кәгъбә, мәсе́х, минба́р, сәҗдә́, хотбә́, тәфси́р, мәзһә́б, гакыйдә́, гыйбадә́т, мөфти́, фәтвә́, саба́х намазы́, өйлә́ намазы́, икенде́ намазы́, ахша́м намазы́, ясту́ намазы́, Алла́һ, Алла́һ Тәгалә́, Алла́һ йорты́.

Кирә́к, кирә́к түге́л, тие́ш, тие́ш түге́л, яры́й, яра́мый.

***Фонетик зарядка.*** Аудиоматериаллар һәм презентация ярдәмендә “фонетик зарядка” ясату. Алдагы темада үтелгән сүзләрнең дөрес әйтелешен кабатлау, тәрҗемәләрен искә төшерү.

***Сөйләм үстерү өчен эш төрләре:***

Диалоглар белән эш. Әзер диалогларны укып аңлау, алардагы әзер сөйләм калыпларын истә калдыру. Диалогларны тәрҗемә итү, тулыландырып язу, әйтү. Сорау яки җавап репликаларын өстәп, диалоглар төзү. Грамматик формаларны сөйләм ситуациясе нигезендә аңлату. Тема буенча тәкъдим ителгән лексик берәмлекләрне һәм сөйләм этикеты үрнәкләрен файдаланып, мөстәкыйль рәвештә диалоглар төзү, үзара сөйләшү. Лексик тема буенча сөйләшү үткәрү. Сөйләмне ишетеп аңлау һәм җавап кайтару. Текстларны уку һәм төп эчтәлегенә төшенү, сорауларга җавап бирү. Таныш булмаган сүзләр белән эш. Текстның эчтәлеген сөйләү. Темага бәйле рәвештә, өйрәнелгән диалоглар нигезендә монологик сөйләм төзергә өйрәнү.

## АЛТЫНЧЫ ТЕМА

## Дини бәйрәмнәр, истәлекле көннәр, изге кичәләр

## (6 сәгать)

Тема үз эченә татар телендә дини бәйрәмнәргә, истәлекле көннәргә, изге кичәләргә караган лексик берәмлекләрне, сөйләм калыпларын ала һәм аларны, сөйләм ситуациясенә карап, дөрес, урынлы куллана белү күнекмәләрен формалаштыру һәм ныгытуны максат итә.

Дини бәйрәмнәр, истәлекле көннәр, изге кичәләр. Хаҗ.

Иялек, юнәлеш, төшем, чыгыш һәм урын-вакыт килешләренә нигезләнгән актив сөйләм калыплары белән таныштыруны дәвам итү. Сыйфат фигыль формаларын сөйләмдә куллану.

***Лексик минимум:*** Бәйрәм, дини бәйрәм, дин кардәшләрем (-ебез), изге кичәләр, ураза, ураза гаете, корбан, корбан гаете, зикер, нәби, вәхи, могҗиза, ахирәт, гает, җеназа, мөхәррәм, гомрә, Зәмзәм, Зәмзә́м суы́, хаҗ, хаҗи́, Коръә́н аяте́, Сафа́ тавы́, Корба́н бәйрәме́, Корба́н гаете́, ураза́, Ураза́ гаете́.

Ү́здыр, ү́ткәр, бәйрә́м ит, ко́тла.

***Фонетик зарядка.*** Аудиоматериаллар һәм презентация ярдәмендә “фонетик зарядка” ясату. Алдагы темада үтелгән сүзләрнең дөрес әйтелешен кабатлау, тәрҗемәләрен искә төшерү.

***Сөйләм үстерү өчен эш төрләре:***

Диалоглар белән эш. Әзер диалогларны укып аңлау, алардагы әзер сөйләм калыпларын истә калдыру. Диалогларны тәрҗемә итү, тулыландырып язу, әйтү. Сорау яки җавап репликаларын өстәп, диалоглар төзү. Грамматик формаларны сөйләм ситуациясе нигезендә аңлату. Тема буенча тәкъдим ителгән лексик берәмлекләрне һәм сөйләм этикеты үрнәкләрен файдаланып, мөстәкыйль рәвештә диалоглар төзү, үзара сөйләшү. Лексик тема буенча сөйләшү үткәрү. Сөйләмне ишетеп аңлау һәм җавап кайтару. Текстларны уку һәм төп эчтәлегенә төшенү, сорауларга җавап бирү. Таныш булмаган сүзләр белән эш. Текстның эчтәлеген сөйләү. Темага бәйле рәвештә, өйрәнелгән диалоглар нигезендә монологик сөйләм төзергә өйрәнү.

## КАБАТЛАУ
## (3 сәгать)

Максаты – курс дәвамында каралган темалар эчендә урын алган актив лексик берәмлекләрне, сөйләм калыпларын искә төшерү, аларның сөйләм ситуациясенә нисбәтле (диалогик һәм монологик сөйләмдә) кулланылыш формаларын кабатлау, тагын бер кат ныгыту.

***Кабатлау өчен эш төрләре:***

– сорау яки җавап репликаларын өстәп, диалоглар төзү;
– текстның төп эчтәлеге буенча сорау-җавап;
– лексик тема буенча әңгәмә;
– аралашу барышында сөйләмне ишетеп аңлау һәм җавап кайтару һ.б.

## КУРС АХЫРЫНДА БЕЛЕМНӘРНЕ ТИКШЕРҮ

Төзелеш-корылышы ягыннан катлаулы булмаган берәр вәгазь тыңлату. Курста укучылар вәгазьнең эчтәлеге буенча сораулар төзи белергә, темага бәйле гади сорауларга җавап бирә алырга тиешләр.

## ФОНЕТИК ЗАРЯДКА ӨЧЕН СҮЗЛӘР

| | |
|---|---|
| [а°]<br>азан [а°за́н]<br>намаз [на°ма́з]<br>Рамазан [ра°маза́н] – Рамазан<br>Салих [са°ли́х] – Салих (муж. имя)<br>ахырзаман [а°хырзама́н] – конец света<br>ак [а°ҡ] – белый | [ә]<br>әни́ – мама<br>әти́ – папа<br>фәрештә́ – ангел<br>хәрам [хәрә́м] – запретный<br>хәди́с – хадис<br>мәче́т – мечеть<br>дәре́с – урок |
| [ө]<br>өй – дом<br>көзге [көзгө́] – зеркало<br>дөнья [дөнйа́] – мир<br>төтен [төтө́н] – дым<br>өстә́л – стол<br>өйлә́ – обеденное время<br>мөселман [мөсөлма́н] – мусульманин<br>өмет [өмө́т] – надежда | [ү]<br>күз – глаз<br>күк – небо<br>үлә́н – трава<br>күзле́к – очки<br>үтү́к – утюг<br>үрнә́к – образец, пример<br>түземле́ – терпеливый<br>сүрә́ – сура<br>үгéт – наставление, увещевание |
| [ғ]<br>Галия [ғәлийә́] – Галия (жен. имя)<br>гасыр [ғасы́р] – век<br>туган [туға́н] – родственник<br>гарәп [ғәрә́п] – араб<br>гомер [ғөмө́р] – жизнь<br>гыйлем [ғилә́м] – знание<br>гадәт [ғәдә́т] – привычка<br>гамәл [ғәмә́л] – поступок | [ҡ]<br>каш [ҡа°ш] – бровь<br>орлык [орло́ҡ] – семя<br>курка [ҡурҡа́] – боится<br>вакыт [wа°ҡы́т] – время<br>каты [ҡа°ты́] – твёрдый<br>йокы [йоҡо́] – сон<br>кош [ҡош] – птица<br>кара [ҡа°ра́] – черный |
| [w]<br>савап [са°wа́п] – воздаяние<br>вакыйга [wа°ҡиғә́] – происшествие, событие<br>вә [wә] – и<br>һава [һа°wа́] – воздух<br>салават [са°лаwа́т] – хвалебная молитва<br>авыру [а°wыру́] – больной<br>вәгазь [wәғә́с] – проповедь<br>вазифа [wа°зыйфа́] – обязанность | [’]<br>тәэсир [тә’си́р] – впечатление, влияние<br>тәэмин [тә’ми́н] – снабжение<br>Коръән [ҡөр’ә́н] – Коран<br>мөэмин [мө’ми́н] – верующий<br>мәсьәлә [мәс’әлә́] – задача, проблема<br>җөрьәт [җөр’ә́т] – решительность, смелость |
| [о]<br>кол [ҡол] – раб<br>корбан [ҡорба́н] – жертва | [җ]<br>җир – земля<br>җиме́ш – фрукт |

| | |
|---|---|
| йорт – дом<br>сорау [сора́w] – вопрос<br>дога [доға́] – молитва<br>мохта́җ – нуждающийся<br>йола́ – обычай<br>боз – лёд | җәй – лето<br>җиләк – ягода<br>җомга [җомға́] – пятница<br>җавап [җа$^{o}$wа́п] – ответ<br>җәннәт – рай<br>җәһәннәм – ад<br>җәмәгать [җәмәғәт] – общественность |
| [h]<br>һәр – каждый<br>һәрвакыт [һәрwақыт] – всегда<br>һәм – и<br>шәһәр – город<br>гөна́һ – грех<br>Алла́һ – Аллах, Всевышний<br>һөнәр – профессия | |

# ФАЙДАЛАНЫЛГАН ӘДӘБИЯТ ИСЕМЛЕГЕ

1. Сафиуллина, Ф.С., Фатхуллова, К.С. Татарский язык. Интенсивный курс/ Ф.С. Сафиуллина, К.С.Фатхуллова. – Казань: Хәтер, 2001. – 448 с.

2. Сафиуллина, Ф.С., Фәтхуллова, К.С. Татар теленә өйрәтү (“Татар теле. Интенсив курс” китабы белән эшләүче укытучылар өчен методик кулланма)/ Ф.С. Сафиуллина, К.С. Фәтхуллова. – Казан: Хәтер, 2001. – 96 б.

3. Сафиуллина, Ф.С. Татарский язык на каждый день. Самоучитель/ Ф.С. Сафиуллина. – Казань: Хәтер, 2001. – 352 с.

4. Сафиуллина, Ф.С., Шарафиева, Г.Р. Учат таблицы и схемы/ Ф.С. Сафиуллина, Г.Р. Шарафиева. – Казань: Магариф, 1998. – 96 с.

5. Фәтхуллова, К.С., Юсупова, Ә.Ш., Денмөхәммәтова, Э.Н. Татарча сөйләшик/ К.С. Фәтхуллова, Ә.Ш. Юсупова, Э.Н. Денмөхәммәтова. – Казан: Тат. кит. нәшр., 2012. – 311 б.

6. Харисов, Ф.Ф., Харисова, Г.Ф., Айдарова, С.Х. Татар теле: чит телле аудиториядә. Ике кисәктә. Беренче кисәк/ Ф.Ф. Харисов, Г.Ф. Харисова, С.Х. Айдарова. – Казан: Мәгариф, 2009. – 231 б.

7. Харисов, Ф.Ф., Харисова, Г.Ф., Айдарова, С.Х. Татар теле: чит телле аудиториядә. Ике кисәктә. Икенче кисәк/ Ф.Ф. Харисов, Г.Ф. Харисова, С.Х. Айдарова. – Казан: Мәгариф, 2009. – 151 б.

8. Шаяхметова, Л.Х. Татарский язык: интенсивный курс. – Казань: Отечество, 2011. – 147 с.

## Электрон чыганаклар

http://www.belem.ru

http://suzlek.tatarstan.ru

http://kitap.net.ru

http://www.tat.com/tat-fr.html

http://tatarile.org

http:// anatele.ef.com.

www.matbugat.ru

www.prav.tatar.ru.

www.Kzn.ru.

www.Wikipedia.ru